**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге составына керүче Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

7 декабрь, 2021 ел № 1

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башлыгының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек, Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында" 2021 елның 23 ноябрендәге 3 номерлы карары нигезендә, 2021 елның 7 декабрендә узган гражданнар җыенының 1 нче номерлы йомгаклау беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Түбән Тегермәнлек авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Түбән Тегермәнлек авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, 1 группа мөмкинчелекләре чикләнгән һәм 80 яшьтән өлкән гражданнардан гайре, 400 сум күләмендә үзара салым кертергә. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

– Түбән Тегермәнлек торак пунктына су җыю скважинасы өчен тирәнлек насосы сатып алу һәм урнаштыру (шартнамә буенча эш өчен түләү);

– Түбән Тегермәнлек торак пунктында урам утларын карап тоту (тору) һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

– Түбән Тегермәнлек авыл клубы мәйданының арткы ягына койма тоту (материал сатып алу, шартнамә нигезендә эш өчен һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү);

– Түбән Тегермәнлек авылында урамнарның юл йөрү өлешләрен карап тоту (тору) (шартнамә нигезендә эш өчен һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү);

– Түбән Тегермәнлек авылында суүткәргечне ремонтлау һәм су белән тәэмин итү системаларын Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге милкенә рәсмиләштерү (материал сатып алу, шартнамә нигезендә эш өчен һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү);

– Түбән Тегермәнлек торак пунктына ККК өчен 3 данә контейнер сатып алу һәм урнаштыру (сатып алу, шартнамә нигезендә эш өчен түләү);

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Түбән Тегермәнлек авылы, Мәктәп урамы, 7Б йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче –
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башлыгы А.Ш.Альмиев

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РЫБНО-СЛОБОДСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ОГРН 1021607354350
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
Р.06-1723/02
СОВЕТ НИЖНЕ-ТИМЕРЛЕКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634001782
ТҮБӘН ТЕГЕРМӘНЛЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ